ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.11.2022 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3162**

«Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм чаралары турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 27 октябрендәге 2968 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 декабрендәге 1213 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм чаралары турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 27 октябрендәге 2968 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм чаралары турында»;

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның (гаилә әгъзаларының), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, контракт буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затларның, Татарстан Республикасында формалашкан «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарның, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарның, Татарстан

Республикасы буенча Эчке эшләр Министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге ярдәм чаралары билгеләргә:»;

4 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 27 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.В. Старостин